ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ӘЛМӘНДӘР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

КАРАР

15 февраль 2019 ел №128

Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында” 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турындагы Кодекс, Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы “Әлмәндәр авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Әлмәндәр авыл җирлеге Советы карар итә:

1. Әлмәндәр авыл җирлеге Советының 2016 ел, 12 февраль 16 нче номерлы карары белән расланган “Авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында” Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 5.7 пунктының 2 пунктчасында. "бакчачылык, яшелчәчелек, дача кулланучылар кооперативларының" сүзләрен төшереп калдырырга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында, мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Апас муниципаль районының рәсми сайтында җирлек бүлегендә урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Әлмәндәр авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Әлмәндәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Зәләлиев